КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 июль г.Казань № 608

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түбән Кама моношәһәрен үстерү чараларын тормышка ашыру буенча эшче төркем төзү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1026 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түбән Кама моношәһәрен үстерү чараларын тормышка ашыру буенча эшче төркем төзү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1026 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 июнь, 512 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Түбән Кама моношәһәрен үстерү чараларын тормышка ашыру буенча эшче төркем турындагы нигезләмәдә:

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Түбән Кама моношәһәрен үстерү чараларын тормышка ашыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәре моноюнәлешле муниципаль берәмлегендә инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү һәм (яки) реконструкцияләү чараларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу турындагы 2017 ел, 22 ноябрь, 06-22-24 нче һәм 2019 ел, 7 июнь, 06-04-38 нче килешүләр (алга таба – Түбән Кама моношәһәре, Килешүләр) нигезендә төзелде.»;

2.1 нче һәм 2.2.2 нче пунктларда «Килешү» сүзен «Килешүләр» сүзенә алыштырырга;

3.1.3 нче һәм 4.6 нчы пунктларда тиешле килешләрдәге «Килешү» сүзен тиешле килешләрдәге «Килешүләр» сүзенә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Түбән Кама моношәһәрен үстерү чараларын тормышка ашыру буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан В.А.Волошинны, Н.А.Таркаеваны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Территориаль үсеш идарәсе башлыгы, эшче төркем секретаре Виктория Владимировна Самсонованы;

«КАМАСТАЛЬ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры Алевтина Александровна Кузьминаны (килешү буенча);

«ЦМК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Булат Фатыйх улы Мотыйгуллинны (килешү буенча);

«Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешмасының проектлар мониторингы департаментына караган инфраструктура проектлары мониторингы блогының өлкән идарәче директоры Анастасия Александровна Нехаеваны (килешү буенча);

Радмир Илдар улы Беляевның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инвестицияләр, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе буенча беренче урынбасары (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин